ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.08.2026 г.Казань № 37-5/тэ-2026

Азнакай муниципаль районының Актүбә ш. т. п. кулланучыларына «Альметьевские тепловые сети» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр булдыру турында» Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты Идарәсе утырышының 19.08.2026 ел, № 24-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т. п. кулланучыларына «Альметьевские тепловые сети» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Альметьевские тепловые сети» ҖЧҖ) тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифларны әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән алып 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.08.2026 елның № 37-5/тэ-2026
карарына кушымта

## Азнакай муниципаль районының Актүбә ш. т. п. кулланучыларына «Альметьевские тепловые сети» ҖЧҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салына торган оешманың исеме, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукция ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг / см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг / см$^2$ дан артыграк | |
| | Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.п. | | | | | | | |
| 1 | «Альметьевские тепловые сети» ҖЧҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән алып 19.08.2026 алып № 37- 5/тэ-2026 30.09.2026 кадәр | 2255,95 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 2553,76 | | | | | |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә) <*> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән алып 19.08.2026 № 37- 5/тэ-2026 30.09.2026 кадәр | 2752,26 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 3115,59 | | | | | |

<* Рәсәй Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, тикшереп тору һәм озата бару бүлеге